РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕКИБЯКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ул. Ленина, д. 31**
**село Верхние Кибя-Кози,**
**422083**
**тел.(884360) факс: 56-5-42**
E-mail: VKbk.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ КИБӘХУҖА АВЫЛЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**Ленин урамы, 31енчейорт,**
**Югары Кибәхуҗа авылы,**
**422083**
**тел. (884360) факс: 56-5-42**
E-mail: VKbk.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318107 ОГРН 1061675010836 ИНН/КПП 1619004443/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№11** **«13» август 2020 ел**

Теләче муниципаль районының Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында

«2020 елның 13 сентябрендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» Татарстан Республикасы Теләче районының 2020 елның 28 июлендәге 14/22 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Теләче муниципаль районының Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- Югары Кибәхуҗа авылы, Ленин ур. “Сәүдә йорты” кибете янындагы мәгълүмат стенды;
- Югары Кибәхуҗа авылы, Ленин ур. “Айнур” кибете янындагы мәгълүмат стенды;
- Максабаш авылы, Татарстан ур. “Сәүдә йорты” кибете янындагы мәгълүмат стенды;

- Төрек-Тәмте авылы, Үзәк ур. “Сәүдә йорты” кибете янындагы мәгълүмат стенды.

2. Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының «Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлар сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында» 2019 елның 27 июль №24 карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча : Югары Кибәхуҗа авылы, Ленин ур., 31 йорт, Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Теләче муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Ф.Р. Мәхмүтов